ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

01.03.2024 г. Казань ___38-од___

«Минем шәҗәрәм»
ел саен үткәрелә торган республика генеалогик
тикшеренүләр конкурсы турында

Шәҗәрә ясау традицияләрен саклап калу һәм үстерү, гаиләдәге бәйләнешләрне һәм буыннар алмашын ныгыту, Татарстан Республикасы һәм гаилә тарихы белән кызыксынуны арттыру, тарихи аң һәм ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләү, шулай ук архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү максатларында

боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы (алга таба – конкурс) турында нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең генеалогиягә кагылышлы мөрәҗәгатьләрне үтәү бүлегенә җаваплы башкаручыларны билгеләргә, расланган Нигезләгә ярашлы рәвештә конкурсны оештырырга һәм үткәрергә.

3. Финанс-икътисад бүлегенә Конкурста җиңүчеләргә акча түләүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган максатчан чаралар хисабына гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында» 2023 елның 9 февралендәге 37-од номерлы боерыгын үз көчен

югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «_01__» ___03___ ___2024___, № _38-од____
боерыгы белән расланды

# «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсын үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, конкурс) конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен, конкурс эшләрен бәяләү критерийларын билгели.

1.2. Конкурсны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты), конкурсны оештыручы - «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «ТР Дәүләт архивы» ДБУ).

1.3. Конкурсны үткәрү тәртибе, биремнең асылы каралган шартлары, нәтиҗәләрне бәяләү критерийлары һәм тәртибе, аларны тәкъдим итү урыны, сроклары һәм тәртибе, бүләкнең зурлыгы һәм формасы, шулай ук конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге ТР Архив буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайты) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «ТР Дәүләт архивы» ДБУ рәсми сайтына (http://ga.tatarstan.ru) (алга таба – «ТР Дәүләт архивы» ДБУ рәсми сайты) конкурс эшләрен кабул итә башлауга кимендә ун календарь көн кала урнаштырыла.

## 2. Конкурсның максаты һәм бурычлары

2.1. Конкурсның төп максаты – шәҗәрә ясау традициясен торгызу, гаилә кыйммәтләрен саклап калуга ярдәм итү.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- шәҗәрә ясау традицияләрен саклап калу һәм үстерү;
- гаилә тарихының ил һәм туган як тарихына катнашы булуын өйрәнү нигезендә балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүгә өлеш кертү;
- гаилә традицияләрен һәм буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү;
- тарих-шәҗәрә тикшеренүләре традицияләрен саклап калу һәм үстерү;
- архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста барлык теләүчеләр биш яшь төркеме буенча катнаша ала:

1 төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучылары;

2 төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 5-8 сыйныф укучылары;

3 төркем – гомуми белем бирү оешмаларының 9-11 сыйныф укучылары, шул исәптән 18 яше тулганнар;

4 төркем – һөнәри белем бирү оешмаларының 18 яшькә кадәрге укучылары;

5 төркем – 18 яшьтән өлкәнрәк физик затлар.

3.2. Конкурста җиңүчеләр һәр яшь төркеме буенча аерым билгеләнә.

3.3. Конкурста катнашуга 14 яшьтән яшьрәк катнашучы гаризасы катнашучы ата-анасының берсе (яки законлы вәкиле) тарафыннан имзалана.

3.4. Конкурска, 1 яшь төркемендә катнашучылардан тыш, бары тик индивидуаль башкарылган эшләр генә кабул ителә.

## 4. Конкурсның оештыру комитеты

4.1. Конкурс үткәрү һәм эшләрне сайлап алу өчен Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында (шәһәр округында) муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) вәкилләреннән, музей хезмәткәрләреннән, фәнни белгечләрдән комиссия функцияләре белән (конкурс эшләрен бәяләү, муниципаль дәрәҗәдә (шәһәр дәрәҗәсендә), яшь төркемнәренә карап, катнашучылар рейтингын төзү һәм сайлап алу) район (шәһәр) оештыру комитетлары төзелә.

4.2. Конкурсны оештыру, үткәрү һәм нәтиҗәләр чыгару өчен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, «ТР Дәүләт архивы вәкилләреннән оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары составында тугыз кешедән гыйбарәт республика оештыру комитеты (алга таба - оештыру комитеты) төзелә.

4.3. Оештыру комитеты функцияләре:

- конкурсны оештыру ягыннан әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итү;
- муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре, секторлары) тарафыннан сайлап алынган конкурс гаризаларын җыю;
- массакүләм мәгълүмат чараларында, «Татарстан Республикасы архивлары» порталында һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, «ТР Дәүләт архивы» ДБУ рәсми сайтларында конкурс барышы турында хәбәр итү;
- конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә җиңүчеләр исемлеген төзү.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 һәм 4.2 пунктларында күрсәтелгән оештыру комитетларының эше аларның утырышларында гамәлгә ашырыла. Әгәр аларда оештыру комитетлары әгъзаларының гомуми санынннан күпчелеге катнашса, утырыш хокукка ия дип санала.

## 5. Конкурс комиссиясе

5.1. Конкурска бирелгән иң яхшы эшләрне бәяләү һәм ачыклау, шулай ук җиңүчеләрне билгеләү өчен конкурс комиссиясе (алга таба – комиссия) төзелә.

5.2. Комиссия ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, Дәүләт архивы, Россия тарихчылар-архивчылар җәмгыятенең Татарстан төбәк бүлеге, «ТР Дәүләт архивы» ДБУ, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары (килешү буенча) вәкилләре, фәнни бергәлек вәкилләре (килешү буенча) арасыннан комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары составында кимендә 9 кешедән төзелә. Комиссия составы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.3. Комиссия эшенә рәис җитәкчелек итә. Ул булмаган очракта, вазыйфалары аның урынбасарына йөкләнә. Конкурс нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынулары булган затлар Комиссия әгъзалары була алмый.

5.4. Комиссия эше аның утырышларында башкарыла. Әгәр аларда комиссия әгъзаларының гомуми саныннан өчтән ике өлеше катнашса, утырыш хокукка ия дип санала.

5.5. Конкурска бирелгән эшләрне бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

- бирелгән материалларны бәяләү критерийларына нигезләнеп бәяләүнең объективлыгы;
- конфиденциальлек.

5.6. Конкурс эшләрен бәяләүне комиссия әгъзалары, бәяләү критерийларына нигезләнеп, эксперт бәяләве алымы белән башкара.

5.7. Комиссия әгъзалары һәр критерий буенча баллар куя һәм алар кушыла. Һәр критерий буенча баллар саны 10 баллы шкала буенча билгеләнә (0 алып 10 кадәр).

Баллар «Индивидуаль бәяләү кәгазьләре»нә кертелә, комиссия әгъзасы имзасы белән таныклана һәм комиссия утырышында рәислек итүчегә тапшырыла (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта).

5.8. Комиссия әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 8 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча куелган балларны кушканнан соң, катнашучыларның йомгаклау рейтингы төзелә, ул комиссия утырышында рәислек итүче һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

5.9. Баллар исәбен тигез җыйган берничә катнашучы булган очракта, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышларның гади күпчелеге нигезендә комиссия тарафыннан билгеләнә. Җыелган тавышлар тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

5.10. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## 6. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

6.1. Конкурс читтән торып үткәрелә. Конкурста катнашучыларның эшләре, 5 төркемдә катнашучыларның эшләреннән тыш, читтән торып 2 этапта карала:

1 этап - муниципаль этап, ул муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре, секторлары) тарафыннан үткәрелә;

2 этап - республика этабы.

Конкурс этапларын үткәрү даталары һәм конкурс документларын тапшыру срогы, конкурста катнашу өчен сайлап алу, гаризалар кабул итү шартлары һәм критерийлары ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана һәм конкурс эшләрен кабул итә башлаганчы кимендә ун календарь көн кала «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының (http://arhiv.tatarstan.ru) һәм «ТР Дәүләт архивы» ДБУ (http://ga.tatarstan.ru) рәсми сайтларына урнаштырыла.

6.2. 5 төркем конкурста катнашучыларының эшләре, муниципаль этапта каралмыйча, турыдан-туры конкурсның икенче этабына җибәрелә.

5 төркем конкурста катнашучылары түбәндәге документлар пакетын электрон рәвештә gen.kon@tatar.ru электрон почта адресына һәм/яки алып килеп биреп, почта аша Столбище ав, Совет ур., 277 адресы буенча «ТР Дәүләт архивы» ДБУ адресына «Минем шәҗәрәм» дигән билге куеп юллый:

конкурста катнашуга гариза (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта);

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гариза (әлеге Нигезләмәгә 2 нче, 3 нче кушымталар);

конкурс материаллары.

6.3. Конкурсның республика этабы 1 төркем, 2 төркем, 3 төркем, 4 төркем өчен һәр төркемнән түбәндәгесанда эшләр җибәрүне күздә тота: Казан шәһәреннән - 7 эш, Чаллы шәһәреннән – 4 эш, Түбән Кама муниципаль районыннан – 3 эш, Татарстан Республикасының калган муниципаль районнарыннан – 1 (берәр) эш,

6.4. Конкурста муниципаль этапта катнашу өчен гариза (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта) электрон рәвештә җибәрелә һәм/яки алып барып биреп тапшырыла, Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе, секторы) адресына почта аша юллана.

6.5. Конкурсның икенче этабында катнашу өчен муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре, секторлары) муниципаль этапта җиңүчеләрнең түбәндәге документлар пакетын электрон рәвештә gen.kon@tatar.ru электрон почта адресына җибәрәләр һәм/яки алып барып биреп тапшыралар, почта аша Столбище ав, Совет ур., 277 адресы буенча «ТР Дәүләт архивы» ДБУ адресына «Минем шәҗәрәм» дигән билге куеп юллый:

конкурста катнашуга гариза (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта);

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гариза (әлеге Нигезләмәгә 2 нче, 3 нче кушымталар);

конкурс материаллары комплекты (Казан шәһәреннән - 7 эш, Чаллы шәһәреннән – 4 эш, Түбән Кама муниципаль районыннан – 3 эш, Татарстан Республикасының калган муниципаль районнарыннан – 1 (берәр) эш);

муниципаль этапта конкурс йомгаклары беркетмәсе (әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта).

6.6. Конкурс материаллары яшь төркемнәренә ярашлы рәвештә түбәндәге форматта тапшырыла:

1 төркем – катнашучы тарафыннан башкарылган иҗади эш (гаилә агачы рәсеме, аңлатмалар белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал һәм тукымалар кулланып башкарылган күләмле эш һ.б.). Бер катнашучыдан эшләр саны чикләнми;

2 төркем - катнашучы тарафыннан башкарылган иҗади эш (гаилә агачының рәсеме, аңлатмалар белән фотоальбомнар, коллажлар, схемалар, плакатлар, аппликация, табигый материал һәм тукымадан файдаланып күләмле эш һ.б.) һәм язма эш (реферат, эссе, инша һ. б.) 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифт белән язылган А4 форматлы 10 биткә кадәр, сулдан - 2 см, уңнан - 1 см, өске һәм аскы яктан 2 шәр см ара калдырыла (битләрнең саны куелган булырга тиеш). Кушымталар күләме чикләнми;

3 төркем – катнашучы тарафыннан башкарылган тикшеренү эше, теләсә нинди форматта ярый (язма эш (14 зурлыгындагы Times New Roman шрифт белән язылган А4 форматлы 15 биткә кадәр күләмле аналитик хисап, сулдан – 2 см, уңнан - 1 см, өске һәм аскы яктан 2 см калдырылган (битләрнең саны куелган булырга тиеш)), видеоэшләр (гаилә тарихы турында өй шартларында төшерелгән фильмнар (10 минутка кадәр), Microsoft Power Point форматындагы презентацияләр (50 слайдка кадәр));

4 төркем - архив документлары нигезендә катнашучы тарафыннан башкарылган проект-тикшеренү эше (фәнни хисап, фәнни мәкалә, доклад);

5 төркем - түбәндәге форматлар буенча (сайлап алынган) конкурс материаллары:

кушымта итеп генеалогик схемалар һәм нәсел агачы бирелгән язма эшләр (рәвеше: эссе яки мәкалә). Төп тасвирламаның күләме – 14 зурлыгындагы Times New Roman шрифт белән язылган А4 форматлы 30 биткә кадәр, сулдан – 2 см, уңнан – 1 см, өске һәм аскы яктан 2 см калдырылган (битләрнең саны куелган булырга тиеш), кушымталар күләме чикләнми;

видеоэшләр – гаилә тарихы турында өй шартларында төшерелгән фильмнар (дәвамлылыгы 60 минутка кадәр);

Microsoft Power Point форматында презентация (50 слайдка кадәр).

6.7. Конкурс материалларында шәҗәрә төзү өчен нигез итеп алынган архив документлары күрсәтелә.

6.8. Конкурска җибәрелгән эшләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

6.9. Конкурска ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты элек үткәргән генеалогик тикшеренүләр конкурсларында катнашкан эшләр кабул ителми.

6.10. Конкурска материаллар тәкъдим итү авторның аларны конкурсны оештыручының чараларында авторлык хокукларын саклап куллануга рөхсәт бирүен аңлата.

6.11. Җибәрелгән материаллар автор(лар)ның ризалыгы белән «Татарстан Республикасының Бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасына кертү өчен файдаланылырга мөмкин.

6.12. Документларны кабул итүнең ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнгән срогы тәмамланганнан соң җибәрелгән материаллар каралмый.

## 7. Конкурс эшләренең эчтәлеге

7.1. Хезмәттә документлар белән раслана торган мәгълүмат кына түгел, ә гаилә тарихыннан булган һәм документлар белән берничек тә раслап булмый торган теләсә нинди кызыклы фактлар да бәян ителергә мөмкин. Аудиофайл рәвешендә яки аңлаешлы телгә күчерелгән текст рәвешендә тәкъдим ителгән әңгәмәләр, истәлекләр һәм интервью материалларын куллану рөхсәт ителә.

Ата-бабаларының иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеге, шул исәптән хезмәт ветераннары, 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында катнашучылар булуы турында мәгълүматлар булса, алар да күрсәтелергә мөмкин.

7.2. Эшләр рус һәм (яки) татар телләрендә тапшырыла.

## 8. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

8.1. 1 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

- конкурсның максатлары һәм бурычларына туры килү (0 алып 10 кадәр балл);
- эшнең бизәлешендәге оригинальлек һәм иҗади якын килү (0 алып 10 кадәр балл);
- идеянең техник яктан тормышка ашырылу дәрәҗәсе (0 алып 10 кадәр балл);
- конкурс эшен әзерләүдәге мөстәкыйльлек дәрәҗәсе (0 алып 10 кадәр балл);
- китерелгән тарихи фактларның дөреслеге (0 алып 10 кадәр балл).

8.2. 2-3 төркемнәр эшләрен бәяләү критерийлары:

- конкурсның максатлары һәм бурычларына туры килү (0 алып 10 кадәр балл);
- китерелгән тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе (0 алып 10 кадәр балл);
- гаилә кыйммәтләрен һәм гореф-гадәтләрен ачу дәрәҗәсе (0 алып 10 кадәр балл);
- үз фамилияңнең барлыкка килүе, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы конфессиягә каравы турында белешмәләрнең булуы һәм нигезләнгәнлеге (0 алып 10 кадәр балл);
- ил һәм туган як тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турындагы белемнәрнең тирәнлеге (0 алып 10 кадәр балл);
- эшнең сәнгать ягыннан кыйммәтләре (әдәби тел, образлы бәян итү, күрсәтмә материалларның бизәлеше сыйфаты) (0 алып 10 кадәр балл);
- кулланыла торган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, гаилә ядкәрләре һ.б.) (0 алып 10 кадәр балл).

8.3. 4 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

- проблеманы тикшерүнең тулылыгы, үз фамилияңнең барлыкка килүе, милли тамырлар, ата-бабаларыңның кайсы конфессиягә каравы, аларның тормышы турында нигезләнгән мәгълүматларны да кертеп (0 алып 10 кадәр балл);

- абруйлы чыганакларга һәм үзе чыгарган нәтиҗәләргә сылтамалар булып, тарихи мәгълүматларны анализлау тирәнлеге (0 алып 10 кадәр балл);

- файдалану мөмкинлеге бирелгән барлык төп архив чыганакларының колачлануы, файдаланылган әдәбиятның зур күләме (0 алып 10 кадәр балл);

- структураның төгәллеге һәм материалны бәян итү эзлеклелеге (0 алып 10 кадәр балл);

- эшнең гамәли һәм фәнни әһәмияте (0 алып 10 кадәр балл).

8.4. 5 төркем эшләрен бәяләү критерийлары:

- конкурсның максатлары һәм бурычларына туры килү (0 алып 10 кадәр балл);

- файдалана торган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, бүләкләр, гаилә оешмалары һ. б.) (0 алып 10 кадәр балл);

- файдала торган архив чыганакларының күптөрлелеге (метрик китаплар, ревизия әкиятләре, исповедные ведомости һ.б.) (0 алып 10 кадәр балл);

- нәсел шәҗәрәсендә күрсәтелгән буыннар саны (кимендә 3) (0 алып 10 кадәр балл);

- үз гаиләсенең килеп чыгышы һәм милли тамырлары турында белемнәрнең тирәнлеге (0 алып 10 кадәр балл);

- нәсел вәкилләренең төбәк һәм ил тарихындагы роле турында белемнәрнең тирәнлеге (0 алып 10 кадәр балл);

- шәҗәрә агачының рәсеме (схемасы) һәм аның тасвирламасы булу (0 алып 10 кадәр балл);

- эшнең сәнгать ягыннан өстенлеге (әдәби тел, образлы бәян итү, бизәлеш осталыгы) һәм эш бизәлешенең техник яктан дөреслеге (бизәлеш таләпләренә туры килү, сылтамалар булу, схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләр куллану һ. б.) (0 алып 10 кадәр балл)

- гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруда һәм үз нәселенең тарихын өйрәнүдә социаль активлык (0 алып 10 кадәр балл);

- эшнең фәнни кыйммәте (0 алып 10 кадәр балл).

## 9. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе, нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

9.1. Документлар пакетын тапшыру төгәлләнгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, комиссия утырышы уздырыла.

9.2. Конкурста җиңүчеләр исемлеге, катнашучыларның йомгаклау рейтингына нигезләнеп, һәр яшь төркеме буенча аерым төзелә.

9.3. Конкурс нәтиҗәләре буенча яшь төркемнәре чикләрендә рейтингта беренче алты урынны алган катнашучылар конкурста җиңүчеләр дип танылa: бер беренче урын, ике икенче урын, өч өченче урын.

9.4. Конкурста җиңүчеләр түбәндәгечә бүләкләнә:

1-4 яшь төркемнәрендә: конкурс дипломнары һәм истәлекле бүләкләр: Станция Яндекс Макс – I урын өчен, Станция Яндекс – II урын өчен, универсаль колакчыннар – III урын өчен;

5 яшь төркемендә: конкурс дипломнары һәм түбәндәге күләмнәрдә акчалата премияләр: 50 мең сум – I урын өчен, 30 мең сум – II урын өчен, 20 мең сум – III урын өчен.

9.5. Конкурс йомгаклары буенча 1-5 яшь төркемнәре арасында, катнашучының яшенә карамастан, дүрт номинация буенча икешәр кызыксындыру бүләге бирелә:

«Үзенчәлекле шәҗәрә» - эшнең бизәлешендәге оригинальлек һәм иҗади якын килү өчен;

«Бай шәҗәрә» – шәҗәрә төзегәндә иң күп буын һәм туганнар санап кителгән;

«Туган телгә мәхәббәт» - эштә туган телне кулланган өчен;

«Сугыш хатын-кыз йөзле була алмый» - 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фронтта яки тылда хатын-кыз туганнарының катнашуы турында кызыклы хикәя өчен.

9.6. Кызыксындыру бүләкләренә ия булучыларга диплом һәм бүләк – «Минем шәҗәрәм» күн папкасы бирелә.

9.7. Гомуми рейтингның түбән булган (эш өчен билгенең яшь төркемнәре чикләрендә барлык критерийлар буенча билгеләрнең гомуми суммасының яртысыннан түбәнрәк булуы), катнашучыларның саны аз булган (яшь төркеме буенча бүләкләнә торган урыннар һәм кызыксындыру урыннары санынннан кимрәк яисә аларга тигез булу), конкурс эшләре конкурс таләпләренә һәм конкурс сайлап алу критерийларына туры килмәгән очракта, комиссия теге яки бу яшь төркемендә урыннар бирми, һәм аерым яшь төркемендә конкурс үткәрелмәгән дип таныла.

9.8. Әлеге Нигезләмәнең 9.7 пунктында күрсәтелгән очракларда оештыру комитеты бүләкләр фондын конкурс нәтиҗәләре буенча яшь төркемнәре чикләрендә рейтинг нигезендә барлык яшь төркемнәрендә җиңүчеләр арасында бүлә.

9.9. Кызыксындыру бүләкләрен бирү һәм бирмәү турындагы карарны комиссия әгъзалары һәм оештыру комитеты коллегиаль кабул итә, һәм ул беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9.10. Конкурста җиңүчеләр исемлеге ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән, комиссиянең йомгаклау утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмәгә кул куелган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

9.11. Конкурста җиңүчеләр исемлекләре боерыкка кул куелган көннән алып 3 эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт архивының рәсми сайтына урнаштырыла.

## 10. Өстәмә мәгълүмат

10.1. Тәкъдим ителгән эшләргә авторлык хокуклары конкурста катнашучыларныкы булып кала.

10.2. Конкурсны оештыручы архив чараларын таныту максатларында, мәгълүмат һәм презентация материалларын ясау өчен конкурс эшләрен, шул исәптән конкурска гаризаларга беркетеп җибәрелгән фотоларны, видеороликларны һәм башка документларны авторлык хокукларын саклап куллану хокукын үзендә калдыра.

10.3. 5 төркем җиңүчеләренә (I урын, II урын, III урын) шәҗәрәләрен аларның ризалыгы белән «Ядкяр» порталына (http://yadkyar.tatar.ru) урнаштыру мөмкинлеге бирелә.

10.4. Барлык конкурс эшләре дә саклау өчен «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» ДБУнә «Минем шәҗәрәм» конкурсы документлары коллекциясе» фондына тапшырыла.

10.5. Җиңүчеләр исемлегенә кермәгән конкурста катнашучыларның барысына да конкурста катнашучылар сертификатлары бирелә, алар җиңүчеләр исемлеге урнаштырылганнан соң бер ай эчендә катнашучының E-mail адресына электрон рәвештә җибәрелә.

«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган
республика генеалогик тикшеренүләр
конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

## «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсында катнашуга гариза

| | |
|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) | |
| Катнашучының яше | |
| Катнашучы укый торган белем бирү оешмасы; Катнашучының эш урыны | |
| Катнашучының яшәү урынының индексы белән тулы адресы | |
| Катнашучының контакт телефоннары | |
| Катнашучының E-mail адресы | |
| Конкурс эшенең исеме | |
| Эш тәкъдим ителгән яшь төркеме | |
| Банк реквизитлары | |

«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган
республика генеалогик тикшеренүләр
конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә рөхсәт

Мин ___________________________________________________________________,
*Конкурста катнашучының ФИАи тулысынча (соңгысы – булган очракта)*
_______________________________________________________________________ укыйм,
элемтә өчен телефоным: _______________________________________________________
«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы үткәрелү кысаларында «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Оператор), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында каралганча, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә үземнең шәхси мәгълүматларымны автоматлаштыру чараларын кулланып эшкәртүгә, Оператор сайтларында (http://arhiv.tatarstan.ru) казанышларым турында мәгълүмат урнаштыруга һәм Конкурс җиңүчеләре турында мәгълүмат урнаштыруга ризалык бирәм.

Моның белән Операторга шәхси мәгълүматларның түбәндә санап кителгән категорияләрен карый торган шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1. ФИАи (соңгысы – булган очракта)
2. Элемтә өчен телефон
3. Мәгариф оешмасы
4. Социаль статус

Шәхси мәгълүматларымны бары тик түбәндәге максатларда файдалануга ризалык бирәм:

- эшне төзү һәм эшкәртү;
- тапшырылган конкурс материалларын карау;
- статистика алып бару;
- Операторның рәсми сайтында конкурс нәтиҗәләрен чыгару;
- югарыда күрсәтелгән максатлар белән бәйле башка гамәлләр.

Минем сурәтләрне «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы үткәрелү кысаларында басма матбугатларда, интернет челтәрендә, радио- һәм телевизион эфирда урнаштырыла торган мәгълүмати һәм башка материалларда файдалануга ризалык бирәм.

Сурәтләрем минем намусыма, вөҗданыма һәм эшлекле абруема тап төшерә торган ысуллар белән файдалана алмый.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык бирелгән вакытыннан алып вакыты чикләнмичә гамәлдә була һәм минем тарафтан, Операторга Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә гади язма рәвештәге гариза тапшырылып, кире алынырга мөмкин.

"___" _________, 20___ ел     ____________________     ________________
(конкурста катнашучы имзасы)     (фамилия, инициаллар)

«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Таратырга шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,_____________________________________________________________________________,
шәхси мәгълүматлар субъектының Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта) тулысынча

элемтә өчен телефон: ____________________, электрон почта адресы ____________________,

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясын нигез итеп алып, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә (ИНН 1655369841, ОГРН 1161690140809, урнашу урыны: Столбище авылы, Совет урамы, 277) (алга таба – Оператор) «Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсын үткәрү кысаларында «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең рәсми сайтында минем хакта мәгълүмат урнаштыру максатларында минем шәхси мәгълүматларымны түбәндәге тәртиптә таратырга ризалык бирүем турында белдерәм:

| Шәхси мәгълүматлар категориясе | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән затлар даирәсенә таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Атасының исеме | | | | |
| | Мәгариф оешмасы | | | | |
| | Социаль статус | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Йөзнең төсле цифрлы фотография сурәте | | | | |

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алачак һәм алар белән башка гамәлләр башкарылачак Операторның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр |
|---|---|
| http:// arhiv.tatarstan.ru | Чикләнмәгән затлар даирәсенә бирү |

Әлеге ризалыкны үз ихтыярым белән бирәм һәм «__» ________, 20__ел алып « __» _________, 20__ ел кадәр гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатуны таләп итү хокукы үземдә кала. Таләп куелган очракта, Оператор кичекмәстән минем шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ________________________ | ________________________ |
| дата | имза | фамилия, инициаллар |

«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

1 төркем эшләренең индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең ФИАи (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 кадәр балл |
| Конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| Эшнең бизәлешендә оригинальлек һәм иҗади якын килү | |
| Идеяне техник яктан гамәлгә ашыру дәрәҗәсе | |
| Конкурс эшен әзерләүдә мөстәкыйльлек дәрәҗәсе | |
| Китерелгән тарихи фактларның дөреслеге | |
| БАРЛЫГЫ | |

2-3 төркем эшләрен индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең ФИАи (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 кадәр балл |
| Конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| Китерелә торган тарихи фактларның дөреслеге, архив чыганакларыннан файдалану дәрәҗәсе | |
| Гаилә кыйммәтләрен һәм гореф-гадәтләрен ачу дәрәҗәсе | |
| Үз нәселе буенча тикшерелгән буыннар саные | |
| Үз фамилиясе барлыкка килү турында, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы конфессиягә каравы турында мәгълүматларның булуы һәм аларның нигезләнгәнлеге | |
| Ил һәм туган як тарихында һәм тормышында нәсел вәкилләренең роле турында белемнәрнең тирәнлеге | |
| Эшнең сәнгать ягыннан уңышлы яклары (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, күрсәтмә материалның бизәлеш сыйфаты) | |
| Кулланыла торган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, гаилә риваятьләре һ.б.ш.) | |
| БАРЛЫГЫ | |

4 төркем эшләрен индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең ФИАи (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 кадәр балл |
| Проблеманы өйрәнү тулылыгы, үз фамилиясенең килеп чыгышы, милли тамырлары, ата-бабаларының кайсы диндә булуы, аларның тормышы турында нигезләнгән белешмәләрне дә кертеп | |
| Абруйлы чыганакларга һәм үзе чыгарган нәтиҗәләргә сылтамалар ясап, | |

| | |
|---|---|
| тарихи белешмәләргә ясалган анализның тирәнлеге | |
| Файдалану мөмкинлеге булган барлык төп архив чыганакларының колачлануы, файдаланылган әдәбиятның күләме зур булу | |
| Структураның төгәллеге һәм бәян ителгән материалның эзлеклелеге | |
| Эшнең гамәли һәм фәнни әһәмияте | |
| БАРЛЫГЫ | |

5 төркем эшләрен индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең ФИАи (соңгысы – булган очракта), конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 кадәр балл |
| Конкурсның максатына һәм бурычларына туры килү | |
| Файдалана торган тарихи чыганакларның күптөрлелеге (документлар, хатлар, бүләкләр, гаилә риваятьләре һ.б.ш.) | |
| Файдалана торган тарихи чыганакларның төрлелеге (метрик китаплар, ревизия әкиятләре, исповедь ведомостьлары һ. б.) | |
| Нәсел агачында күрсәтелгән буыннар саны (кимендә 3) | |
| Төбәк һәм ил тормышы тарихында нәсел вәкилләре турында бирелгән тарихи мәгълүматларның төгәллеге, чыганакларга сылтама биреп, һәм үзе ясаган нәтиҗәләр | |
| Нәсел агачының рәсеме (схемасы) һәм аның тасвирламасы булу | |
| Эшнең сәнгать ягыннан уңышлы яклары (әдәби тел, бәян итүнең образлылыгы, рәсем осталыгы) һәм эшнең бизәлешенең техник ягы дөрес башкарылу (бизәлеш таләпләренә туры килү, сылтамалар булу, схемалар, рәсемнәр, фоторәсемнәр кулланылу һ.б.) | |
| Гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруда һәм үз нәселенең тарихын өйрәнүдә социаль активлык | |
| Эшнең фәнни әһәмияте | |
| БАРЛЫГЫ | |

«___» ___________, 20__ ел _________________________ / _________________________

Төзү датасы Комиссия әгъзасы имзасы Бәяләмәдәге имзаны киңәйтеп күрсәтү

«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсы турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

«Минем шәҗәрәм» ел саен үткәрелә торган республика генеалогик тикшеренүләр конкурсының муниципаль этабында комиссия утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы ____________ муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (Идарәсе, секторы)

Архив бүлегенең (Идарәсенең, секторының) почта адресы,
________________________________________________________________________________________
(индексы, муниципаль район, шәһәр, район, урам, йорт)

e-mail____________________________

Муниципаль архив җитәкчесенең Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта) (тулысынча), телефон
________________________________________________________________________________________

Конкурсның муниципаль этабы комиссия рәисе Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта) (тулысынча)
________________________________________________________________________________________

Утырыш датасы ___________________________________________________________________________

Конкурсның республика этабына түбәндәге эшләрне тәкъдим итәргә:

1 яшь төркеме_______________________________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

2 яшь төркеме_______________________________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

3 яшь төркеме_______________________________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

4 яшь төркеме_______________________________________________________________________
(эшнең исеме) (авторның Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), авторның туган елы)

Комиссия әгъзалары имзалары:
(имза) (Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), вазыйфа)_____________________________

(имза) (Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), вазыйфа) _____________________________

(имза) (Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), вазыйфа) _____________________________

Беркетмә расланды___________________________________________
(муниципаль этапның комиссия рәисе имзасы)